ГЛАВА КОРГУЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная площадь, д.1, с. Коргуза,
422586

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАРАГУЖА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 1 нче йорт, Карагуҗа авылы,
422586

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48,

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

02.04.2024 с. Коргуза 01

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48

«Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлегенең Егидерево авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 15 ноябрендәге 01 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү 22.11.2013 ел № 90 тәртибенең 2 пункты (29.11.2023 ел № 1532 редакциясендә) нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлегенең Егидерево авылына гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 15 ноябрендәге 01 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2024 елның 12 апреленә гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:
«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлегенең Егидерево авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 15 ноябрендәге 01 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы?:
- коеларны төзекләндерү, аларга якын урнашкан территорияне төзекләндерү (су башнясы территориясен һәм скважинаны каплау җайланмасын төзекләндерү).

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Егидерево кибете бинасы янында түбәндәге адрес буенча халык җыенын уздырырга: Егидерево авылы, Үзәк урамы 9.30 сәгатьтә.
4. Карагуҗа авыл җирлеге Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Карагуҗа авыл җирлеге башлыгы Д.В.Плохов